**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
КАРАРЫ

2023 елның 12 декабре    № 66    Уруссу ш.т.п.

Яңа редакциядә "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү мөһимлеге булмавы турында" карарны раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирлекләре территорияләрен социаль-икътисадый үстерүнең расланган стратегиясе булмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә, Иске Каразирек, Ташкичү авыл җирлекләре генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмауны;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә, Иске Каразирек, Ташкичү, Урыссу авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында» 2022 елның 11 мартындагы 16 номерлы карары үз көчен югалтуын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының « Татарстан Республикасы Рәсми» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
 Ютмуниципаль районы
башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы
рәисе                                                   А.Ә. Шәфигуллин